СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

___________________ с. Сарманово №_______________

**Сарман муниципаль район территориясендә**
**милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гамәлгә ашыру турында**

Сарман муниципаль районы территориясендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гамәлгә ашыру турында Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, ведомствоара эшче төркем җитәкчесе Сәхипова И. Р. мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглауны алып бару һәм низаглы хәлләрне иртә кисәтү эшен дәвам итү.

3. Сарман муниципаль районында милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык атмосферасын ныгыту эшендә барлык җирле үзидарә органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә.

4. ТАССР оешуга 100 ел һәм Сарман муниципаль районының 90 еллыгы бәйрәм символикасы логотипларын массакүләм мәгълүмат чараларында һәм районда үткәрелә торган чараларны рәсмиләштергәндә куллануны һәм чаралар планын үтәүне тәэмин итәргә.

5.Җирле үзидарә органнары, оешма һәм предприятие җитәкчеләренә үз һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләренә Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү предметына җентекле мониторинг үткәрергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципального район
Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин